ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА ШАШЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШАШИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422008 Республика Татарстан Атнинский район с. Новые Шаши. Тел. 3-23-23

# КАРАР

“17” гыйнвар 2022 ел — № 1

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Яңа Шашы авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 6 августында 20 нче номерлы карары белән кабул ителгән “Агачларны һәм куакларны кисүгә, кронлауга,утыртуга, күчереп утыртуга,газонны сүтүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына” үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру» турындагы Федераль закон нигезендә, Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Яңа Шашы авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 06 августындагы 20 нче номерлы карары белән расланган «Агачларны һәм куакларны кисүгә, кронлауга,утыртуга, күчереп утыртуга, газонны сүтүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына» түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:
   1.1. 2.3.1 пунктының 2 пунктчасында. "агачлар, куакларның авариясе турында бәяләмә белән» сүзләрен төшереп калдырырга;
   1.2. 2.4.1 пунктының дүртенче абзацын төшереп калдырырга;
   1.3. 2.5.4. нче пунктны төшереп калдырырга;
   1.4. 2.6.1 пунктының 4, 5, 7 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә Башкарма комитет яки муниципаль район җирле үзидарә органы " сүзләренә алмаштырырга»;
   1.5. 2.6.1 пунктының 6, 11 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы яки Башкарма комитет " сүзләренә алмаштырырга»;
   1.6. 2.6.3.пунктында «Башкарма комитетның структур бүлекчәсе» сүзләрен «муниципаль районның җирле үзидарә органнары,башкарма комитет " сүзләренә алмаштырырга;
   1.7. 2.8.2 пунктының 2 пунктчасында «гаризада күрсәтелгән яшел үсентеләрне тикшерү нәтиҗәсендә яшел үсентеләрнең сүтү мөһимлеген раслый алмаган очракта (авария хәлендәге агачларны)” сүзләрен төшереп калдырырга;
   1.8. 2.8.2 пунктының 5 пунктчасындагы "(авария-торгызу эшләре үткәрүгә яки бик мөхим булганда яшел үсентеләрне сүтүгә бәйле очраклардан тыш (авария хәлендәге агачларның аву куркынычын бетерү өчен)” сүзләрен төшереп калдырырга;
   1.9. 2.8.4 пунктындагы “2 нче кушымтада" сүзләрен «3 нче кушымтада» сүзләренә алмаштырырга;
   1.10. 3.4.2 пунктының дүртенче абзацындагы “, шулай ук, авария-торгызу эшләре үткәрү өчен яисә яшел үсентеләрне сүтү бик мөһим булганда яшел үсентеләрне кисүгә рөхсәт сорап мөрәҗәгать иткән очракта (авария

хәлендәге агачларның аву куркынычын бетерү өчен)" сүзләрен төшереп калдырырга;

1.11. 3.5.2.3 пунктын төшереп калдырырга;

1.12. 3.5.5 пунктындагы «; мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап авария-торгызу эшләрен башкарганда яисә яшел үсентеләрне сүтү бик мөһим булганда мөрәҗәгать иткән очракта (авария хәлендәге агачларның аву куркынычын бетерү өчен) – ике эш көне» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.13. Регламентның 2 нче кушымтасында "авария хәлендәге агачлар кыска вакыт эчендә киселергә тиеш.» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Яңа Шашы авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Сабирҗанов М.С.